

# ЧИШМӘ БАШЫ

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Арча 8нче балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе

№3 2025ел
ноябрь

*Ата –аналар һәм балалар өчен мәгълүмати-таныш белү газетасы*

- **Әниләр турында мәкальләр һәм әйтемнәр.**
- **ЯҢАЛЫКЛАР!**
- **Күзгә сулыклардагы куркынычсызлык айлыгы**
- **Әниләр көне**

## Безнең әни

Кем тегә матур күлмәкләр,
Кем ясый асыл бизәкләр,
Кем тәмле ашлар пешерә,
Гел сине искә төшерә?

Кая барсаң, күз алдында,
Һәрчак күңелеңдә яши?
Ул – безнең иң якын кеше,
Ул, белегез, безнең әни.

Ф.Рәхимголова



**Әниләр турында мәкальләр һәм әйтемнәр.**

•Ана җылысы — кояш җылысы.
•Яктылык — кояш янында, яхшылык — әни янында.
•Ана йөрәге — бала өчен дәрья.
•Ана балага авызыннан өзеп каптыра.
•Ана күңеле — балада, бала күңеле — далада.
•Ана ачуы — язгы кар: күп булса да тиз эри.
•Ана — шәфкать диңгезе.
•Ана яхшылыгын авырсаң белерсең.
•Анасыз корт бал җыймас, бал җыйса да мул җыймас.
•Өйнең яме ана белән.
•Үз анасын зурлаган, кеше анасын хурламас.



# ЯҢАЛЫКЛАР!




- Знче номерлы башлангыч мәктәп-балалар бакчасында мәктәпкә әзерлек төркеменә йөрүче балалары өчен татар теленнән "Татарча өйрәнәм" дип аталган районкүләм олимпиада булып узды. Анда безнең бакчадан Галиуллин Радель һәм Гарифуллина Диләрә катнашты



- “Мәктәптә футбол” бөтенроссия фестивале кысаларында безнең балалар бакчасында “Футбол каруселе” дигән кызыклы спорт чарасы үткәрелде. Фестивальда өлкән һәм әзерлек төркемнәрендә тәрбияләнүчеләр катнашты, анда яшь спортчылар физкультура буенча инструктор җитәкчелегендә туп, җитезлек, тизлек, игътибар, берләшү осталыгына ярыштылар.




- 14 нче ноябрь көнне Арча 8нче балалар бакчасы хезмәткәрләре дөньякүләм "Татарча диктант" акциясендә катнашты. Чарада 29 кеше диктант язды.




- Бакчабыз тәрбиячесе Гөлгенә Мосавировна бөек татар шагыйре Габдулла Тукайга багышланган "Тукай рухы яши күңелләрдә" исемле өстәл календаре ясау бәйгесендә 3 урын алды.



- 2025 елның 20 ноябрендә Татарстан Республикасының Арча, Әтнә, Кукмара,Саба һәм Теләче муниципаль районнарының мәктәпкәчә   учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләр арасында «Күңелле стартлар» республи-какүләм спорт уеннары узды. «Арча» спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе базасында 25 балалар бакчасыннан 50 яшь спортчы җыелды. Барлык командаларның да нәтиҗәләре искиткеч булды! Уеннарда катнашкан һәрбер бала медаль, диплом һәм бүләккә ия булды. Безнең бакчадан 2 команда катнашты һәм 2, 3 урыннар яуладылар.



- 20 ноябрь көнне Яңа Кенәр интернат-мәктәбендә бадминтон һәм өстәл теннисы буенча беренчел профсоюз оешмалары әгъзалары арасында зона ярышлары узды. Ярышларда призлы урыннарны алган безнең хезмәткәрләр дә кат нашты. Гөлназ Мансуровна теннис буенча 1 урынны яулады, Алсина Хаҗиәхмәт кызы 3 урын бадминтон буенча




- Арча шәһәренең 4нче балалар бакчасында "Әни белән бергә" дип исемләнгән җыр бәйгесе булып узды. Безнең балалар бакчасыннан Габбасов Ранель әнисе Сабина белән катнашты. Алар үзләренең бию осталыкларын күрсәтеп 2 урынга лаек булдылар!



- Тәрбияче Нәзирә Зөфәр кызы педагоглар арасында "ДОУ педагогының иң яхшы мастер-классы" муниципаль конкурсында катнашты һәм Гран-При иясе булды.

# Көзге сулыклардагы куркынычсызлык айлыгы

Салкыннар башлану белән, су боз катламының барлыкка килүе күзәтелә, ул балык тотарга, тимераякта шуарга яратучыларны үзенә җәлеп итә. Әмма, ел саен күп кенә кешеләр саклык чараларна игътибар итми һәм, юка бозга чыга, шуның белән үз тормышын куркыныч астына куя.

Бозда үз-үзеңне саксыз тоту имгәнүләр, кителмәгән боз киту һәм салкын суга яки боз астына төшү куркынычы бик зур. Шәхси куркынычсызлык кагыйдәләрен һәм чараларын үтәсәң, боздагы һәлакәтләрдән котылырга мөмкин. Сулыкларда фаҗигаләрнең иң еш сәбәпләреннән берсе – кешеләрнең бозда үз-үзен җавапсыз тотышы.

Көзге сулыклардагы куркынычсызлык айлыгы кысаларында безнең балалар бакчасында барлык төркемнәрдә дә төрле чаралар үтте. Балалар сулыклардагы куркыныч ситуацияләр сурәтләнгән картиналар буенча әңгәмәдә катнаштылар, рәсемнәр буядылар, табышмаклар әйтештеләр һәм суда батучыларны коткару алымнарын ныгыттылар. Мондый дәресләр балаларга мөһим кагыйдәләрне үзләштерергә генә түгел, вакытны күңелле һәм кызыклы итеп үткәрергә дә ярдәм итә. Алынган белемнәр киләчәктә кирәк булыр һәм суда куркыныч хәлләрдән качарга ярдәм итәр дип ышанабыз.













# Әниләр көне




Әнием иң назлы, яратучан, игелекле, бөтен дөньяда бердәнбер.  Балалар бакчасында Әниләр көнен бәйрәм итү инде яхшы традициягә әверелде, аның төп максаты- мәктәпкәчә яшьтәге балаларда анага карата ярату һәм хөрмәт тәрбияләү, балаларның иҗади сәләтләрен үстерү һәм бәйрәмнең уңайлы, өй атмосферасын булдыру. Бу бәйрәмгә беркем дә битараф кала алмый. Нәкъ менә шуңа күрә безнең балалар бакчасында Әниләр көненә бөтен бала да ныклап әзерләнде. Балалар үз куллары белән әниләренә бүләкләр әзерләделәр. Алар яраткан әниләрен күңелгә үтеп керерлек шигырьләре белән котладылар, назлы һәм игелекле җырлар җырладылар, күңелле биюләр башкардылар. Ә әниләр яраткан кызларына һәм улларына төрле Шатлык конкурсларында бик теләп катнаштылар. Бәйрәмгә килгән барлык әниләр дә  яктылык, мәхәббәт, бәхет һәм наз яктысы белән балкып тордылар.

Шулай ук бәйрәмдә мәртәбәле кунаклар Арча районындагы “Юл хәрәкәте иминлеге” ДБУнең профилактика бүлеге начальнигы Мөхәммәтҗанова Э.Г. , Россия Эчке эшләр министрлыгының Арча районы буенча балигъ булмаганнарның эшләре буенча инспекторы Гыйбадуллина Г.З., шәһәр китапханәсе хезмәткәре - N1 филиалы "Арча цетраллаштырылган китапханә системасы" хезмәткәре Ибәтуллина Н.В., район балалар китапханәсе хезмәткәре Байкова Г.Р. булдылар.




































*Баш мөхәррир -- татар теленә өйрәтү буенча тәрбияче: Кәримова Гүзәл Рафаил кызы*
*Мөхәррир урынбасары - логопед Шәрипова Алсинә Хаҗиәхмәт кызы*